# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Мачаклы-Баш торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**17 ноябрь 2025 ел** **№2**

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45, 69 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге Мачаклы-Баш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 һәм 3 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Мачаклы-Баш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электр товарлары сатып алу, урам яктырткычларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктырткычларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (сатып алу, төяү, ташу, вак таш салу Урман буе урамында).
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (чүп-чар җыю, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштырып халыкка җиткерергә: Мачаклы-Баш авылы, Урман буе урамы, 15 йорт каршында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Галиева

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САПЕЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1643002...
КПП 164301001